**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**ГЛАВА КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**29 октябрь 2021 ел** **№ 2**

## Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены билгеләп кую турында.

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставының 24 статьясына таянып, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пуктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Биектау тимер юл станциясе поселогы Комсомольская урамы адресы буенча, балалар мәйданчыгы янында, 2021 елның 14 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пуктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Биектау тимер юл станциясе поселогы Гагарина урамы адресы буенча,1нче номерлы мәктәп бинасы янында, 2021 елның 14 ноябрендә 12 сәгать 30 минутта билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пуктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын Биектау тимер юл станциясе поселогы Гагарина урамы адресы буенча, мунча бинасы янында, 2021 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пуктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын Биектау тимер юл станциясе поселогы Школьная урамы адресы буенча, Саклык банкы бинасы янында, 2021 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта билгеләргә.
5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл

җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пуктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын Биектау тимер юл станциясе поселогы Станционная урамы, 4 йорт адресы буенча, (балалар мәйданчыгы янында), 2021 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пуктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын Биектау тимер юл станциясе поселогы Пионерская урамы адресы буенча, райгаз бинасы янында, 2021 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 30 минутта билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пуктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының җиденче этабын Биектау тимер юл станциясе поселогы Профсоюзный урамы һәм Профсоюзный урамы-1 переулок киселешендә адресы буенча, 2021 елның 14 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта билгеләргә.

8. Халык җыенын үткәрү өчен Биектау тимер юл станциясе поселогында яшәүчеләр исемлеге территориаль билге буенча бүленгән:

8.1. Беренче этап – Комсомольская урамы;

8.2. Икенче этап –Заречная, Садовая урамнары, Гагарина урамы (1 йорттан 14 йортка кадәр), Стадионная, Лесная, Пролетарская урамнары, Школьная урамы (1 йорттан 10 йортка кадәр);

8.3. Өченче этап –Зеленая, 2-нче Зеленая, Садри Масхуди урамнары, Гагарина урамы (14А йорттан ахырына кадәр), Школьная урамы (21 йорттан ахырына кадәр), Азина, Кооперативная урамнары;

8.4. Дүртенче этап –Чернышевского, Советская урамнары, Станционная урамы (11 йорттан 21 йортка кадәр), К.Сагдиева урамы (1, 2, 3 йортлар);

8.5. Бишенче этап –К.Сагдиева урамы (4, 5, 6 йортлар) Станционная урамы (4, 8 йортлар)

8.6. Алтынчы этап –Леонова, Песчаная, Калужская урамнары, Пионерская урамы (23 йорттан 41 йортка кадәр, 51, 59, 64 йортлар), Профсоюзная урамы (1 йорттан 24 йортка кадәр, 28, 30 йортлар), Черноморская урамы (1 йорттан 12 йортка кадәр);

8.7. Җиденче этап – Черноморская урамы (йортларның калган өлеше), Профсоюзная урамы (йортларның калган өлеше), Профсоюзный урамы-1 переулок, Профсоюзный урамы-2 переулок, Пионерская урамы (йортларның калган өлеше).

9. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясе поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга

- Биектау тимер юл станциясе поселогында поселок эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау
- Биектау тимер юл станциясе поселогында контейнер мәйданчыкларын, павильоннарны карап тоту

белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

10. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

11. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.Р.Никитенко